**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 14 сентябрь № 641

г. Казань

Социаль инфраструктура, тышкы төзекләндерү объектларын, гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм инженерлык коммуникацияләрен төзү, реконструкцияләү, агымдагы һәм капиталь ремонтлау чыгымнары мониторингын гамәлгә ашыру регламентын раслау турында

Социаль инфраструктура, тышкы төзекләндерү объектларын, гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм инженерлык коммуникацияләрен төзүгә, реконструкцияләүгә, агымдагы һәм капиталь ремонтлауга финанс ресурсларын планлаштыру һәм файдалану буенча нәтиҗәле карарлар кабул итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Социаль инфраструктура, тышкы төзекләндерү объектларын, гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм инженерлык коммуникацияләрен төзү, реконструкцияләү, агымдагы һәм капиталь ремонтлау чыгымнары мониторингын гамәлгә ашыру регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Социаль инфраструктура, тышкы төзекләндерү объектларын, гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм инженерлык коммуникацияләрен төзү, реконструкцияләү, агымдагы һәм капиталь ремонтлау чыгымнары турында мәгълүмат җыю, туплау, эшкәртү һәм анализлау «Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте» дәүләт мәгълүмат системасының «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне планлаштыру һәм мониторинглау буенча мәгълүмат ресурсын формалаштыруның ярдәм ведомствоара системасы» (алга таба – Ярдәм система) функциональ ярдәмче системасы составында гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә 2016 елның 30 октябренә кадәр:

«Социаль инфраструктура, тышкы төзекләндерү объектларын, гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм инженерлык коммуникацияләрен төзү, реконструкцияләү, агымдагы һәм капиталь ремонтлау чыгымнары мониторингы» модулен (алга таба – Модуль) төзү юлы белән Бердәм системаны модификацияләүгә техник таләпләр (алга таба – техник таләпләр) әзерләргә;

дәүләт учреждениесенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планы һәм дәүләт учреждениесенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү турындагы хисап составына «Биналарга, корылмаларга агымдагы ремонт» дигән өстәмә икътисадый кодны кертүне күздә тотып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы карамагындагы дәүләт учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын төзү һәм раслау буенча үрнәк тәртипне раслау турында» 2010 ел, 30 декабрь, 1173 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында тәкъдимнәр кертергә.

4. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына 2016 елның 30 декабренә кадәр техник таләпләр нигезендә Модульнең программа белән тәэмин ителешен Бердәм системаның «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрне норматив финанслауны, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр тарафыннан хезмәтләр күрсәтү һәм тотуга бюджет ихтыяҗын исәпләүнең мәгълүмат-аналитика системасы» программасы белән тәэмин ителешенә кертүне тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына 2016 елның 30 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне планлаштыру һәм мониторинглау буенча мәгълүмат ресурсын формалаштыруның бердәм ведомствоара системасы турында» 2012 ел, 20 октябрь, 890 нчы карары белән билгеләнгән тәртип нигезендә Бердәм системада Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды акчасы исәбеннән финанслана торган ведомство буйсынуындагы оешмаларның бәяләмәләрен яңартырга һәм актуаль хәлдә тотарга.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 14 сентябрь, 641 нче карары белән расланды

**Социаль инфраструктура, тышкы төзекләндерү объектларын, гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм инженерлык коммуникацияләрен төзү, реконструкцияләү, агымдагы һәм капиталь ремонтлау чыгымнары мониторингын гамәлгә ашыру регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент социаль инфраструктура (социаль өлкә – мәдәният, мәгариф, сәламәтлек саклау, яшьләр сәясәте, социаль яклау учреждениеләре, спорт һәм сәламәтләндерү корылмалары), тышкы төзекләндерү объектларын, гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм инженерлык коммуникацияләрен төзү, реконструкцияләү, агымдагы һәм капиталь ремонтлау чыгымнары турында мәгълүмат җыю, эшкәртү һәм анализлау тәртибен билгели.

1.2. Социаль инфраструктура, тышкы төзекләндерү объектларын, гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм инженерлык коммуникацияләрен төзү, реконструкцияләү, агымдагы һәм капиталь ремонтлау чыгымнары мониторингында (алга таба – мониторинг) төп катнашучылар булып түбәндәгеләр тора:

а) Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы;

б) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;

в) Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты;

г) Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы;

д) Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы;

е) Татарстан Республикасы муниципаль районнарының, шәһәр округларының җирле үзидарә органнары;

ж) «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе.

1.3. Мониторинг түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

а) «Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте» дәүләт мәгълүмат системасының «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне планлаштыру һәм мониторинглау буенча мәгълүмат ресурсын формалаштыруның бердәм ведомствоара системасы» (алга таба – Бердәм система) функциональ ярдәмче системасында мәгълүмат кертү өлешендә:

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы тарафыннан – төзелеш, капиталь ремонт һәм реконструкцияләүнең төбәк

программалары нигезендә башкарыла торган капиталь төзелеш объектларын төзү, капиталь ремонтлау, реконструкцияләү чыгымнарына мөнәсәбәтле;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан – 3 млн.сумнан артык булмаган суммага агымдагы һәм капиталь ремонт үткәргәндә дәүләт йөкләмәләре составында күрсәтелми торган ведомство буйсынуындагы социаль хезмәт күрсәтү оешмалары чыгымнарына мөнәсәбәтле;

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан – төбәк һәм муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын, күперләрне һәм башка транспорт һәм инженерлыклык корылмаларын, гомуми файдаланудагы автомобиль юллары челтәре белән ел буе элемтә булмаган авыл торак пунктларына кадәр җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы каты өслекле автомобиль юлларын, федераль әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын, күперләрне һәм башка транспорт һәм инженерлыклык корылмаларын төзү, ремонтлау, капиталь ремонтлау, реконструкцияләү чыгымнарына мөнәсәбәтле;

Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан – инвестиция программаларын гамәлгә ашыра торган җылылык белән тәэмин итүче оешмаларны төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау чыгымнарына мөнәсәбәтле;

муниципаль районнарның, шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан – муниципаль төзелеш программалары нигезендә муниципаль социаль инфраструктура объектларын төзү, реконструкцияләү, ремонтлау һәм капиталь ремонтлау, шәһәр округларының, муниципаль районнарның, җирлекләрнең җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын, җирле әһәмияттәге тышкы төзекләндерү объектларын капиталь ремонтлау һәм реконструкцияләү чыгымнарына мөнәсәбәтле;

б) Бердәм системада мәгълүмат эшкәртү өлешендә – «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан;

в) Бердәм системада мәгълүмат анализлау өлешендә – Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан – төбәк һәм муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын, күперләрне һәм башка транспорт һәм инженерлыклык корылмаларын, гомуми файдаланудагы автомобиль юллары челтәре белән ел буе элемтә булмаган авыл торак пунктларына кадәр җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы каты өслекле автомобиль юлларын, федераль әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын, күперләрне һәм башка транспорт һәм инженерлыклык корылмаларын төзү, ремонтлау, капиталь ремонтлау, реконструкцияләү чыгымнарына мөнәсәбәтле;

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан – социаль инфраструктура объектларын, җирле әһәмияттәге тышкы төзекләндерү объектларын (юллардан, күперләрдән, юлүткәргечләрдән һәм тоннелльләрдән тыш), инженерлыклык коммуникацияләре

объектларын төзү, капиталь ремонтлау, реконструкцияләү чыгымнарына мөнәсәбәтле.

1.4. Социаль инфраструктура, тышкы төзекләндерү объектларын, гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм инженерлык коммуникацияләрен төзү, реконструкцияләү, агымдагы һәм капиталь ремонтлау чыгымнары турында мәгълүмат әлеге Регламентның 1.2 нче пунктындагы «а» – «е» пунктчаларында аталган мониторингта катнашучылар тарафыннан Бердәм система составында «Социаль инфраструктура, тышкы төзекләндерү объектларын, гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм инженерлык коммуникацияләрен төзү, реконструкцияләү, агымдагы һәм капиталь ремонтлау чыгымнары мониторингы» модуленә (алга таба – Модуль) җибәрелә.

1.5. Мониторингта катнашучыларның Модульгә мәгълүмат кертүе «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла торган технологик күрсәтмәләр нигезендә башкарыла.

## 2. Мониторингта катнашучыларның мәгълүмат кертү тәртибе

2.1. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, әлеге Регламентка теркәлгән 1 нче кушымтада китерелгән форма буенча Бердәм системада урнаштыру өчен, «Татарстан Республикасы Төзелеш комплексы» дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – «ТР Төзелеш комплексы» ДМС) төзелеш, капиталь ремонт һәм реконструкцияләүнең төбәк программалары нигезендә башкарыла торган капиталь төзелеш объектларын төзү, капиталь ремонтлау, реконструкцияләү чыгымнары турындагы мәгълүматтан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итә.

2.2. Татарстан Республикасы муниципаль районнарының, шәһәр округларының җирле үзидарә органнары (килешү буенча) түбәндәгеләрне тәэмин итә:

а) хисап елыннан соң килә торган айның 20 сенә кадәр һәм аларны «ТР Төзелеш комплексы» ДМС системасына тоташтырган елдан соң килә торган елга кадәр киләсе елларда Модуль веб-интерфейсының экрандагы формасын тутыру юлы белән муниципаль социаль өлкә учреждениеләренә, җирле әһәмияттәге тышкы төзекләндерү объектларына (юллардан, күперләрдән, юлүткәргечләрдән һәм тоннелльләрдән тыш) мөнәсәбәтле төзелеш, капиталь ремонтлау, реконструкцияләүнең муниципаль программалары нигезендә башкарыла торган капиталь ремонт, реконструкцияләү, төзелеш чыгымнары турындагы мәгълүматны Модульгә кертү.

Кертелә торган мәгълүмат составы әлеге Регламентка теркәлгән 2 һәм 3 нче кушымталарда китерелә;

б) хисап елыннан соң килә торган айның 20 сенә кадәр муниципаль районнарның, шәһәр округларының, җирлекләрнең җирле әһәмияттәге гомуми

файдаланудагы автомобиль юлларын, күперләрне һәм башка транспорт һәм инженерлыклык корылмаларын ремонтлау, капиталь ремонтлау, реконструкцияләү һәм төзү чыгымнары турында хисап мәгълүматын Модульгә кертү:

әлеге Регламентка теркәлгән 4 һәм 5 нче кушымталарда китерелгән формалар нигезендә электрон документлар әйләнеше системасының элемтә каналлары буенча;

электрон документлар әйләнеше системасының элемтә каналлары буенча яки әлеге Регламентка теркәлгән 6 нчы һәм 7 нче кушымталар нигезендә Модуль веб-интерфейсының экрандагы формасын тутыру юлы белән.

2.3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы хисап елыннан соң килә торган айның 20 сенә кадәр һәм аны «ТР Төзелеш комплексы» ДМС системасына тоташтырган елдан соң килә торган елга кадәр киләсе елларда әлеге Регламентка теркәлгән 2 нче кушымта нигезендә Модуль веб-интерфейсының экрандагы формасын тутыру юлы белән Модульгә ведомство буйсынуындагы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына мөнәсәбәтле агымдагы һәм капиталь ремонт чыгымнары турында мәгълүмат кертүне тәэмин итә.

2.4. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы түбәндәгеләрне тәэмин итә:

а) муниципаль районнарның, шәһәр округларының җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан кертелгән җирле әһәмияттәге социаль өлкә оешмаларын, тышкы төзекләндерү объектларын (юллардан, күперләрдән, юлүткәргечләрдән һәм тоннелльләрдән тыш) капиталь ремонтлау, реконструкцияләү, төзү чыгымнары турындагы мәгълүматны әлеге Регламентның 2.2 нче пунктындагы «а» пунктчасы һәм 2.3 нче пункт нигезендә Модульгә кертү процессында раслауны;

б) ел саен хисап елыннан соң килә торган айның 20 сенә кадәр «Ачык татарстан» мәгълүмат ресурсына муниципаль берәмлекләр, оешмалар яктылыгында су белән тәэмин итү, су бүлү, агынты суларны чистарту өлкәсендә гамәлгә ашырыла торган инвестиция программалары, аларны финанслауның планлаштырылган һәм факттагы күләмнәре хакында мәгълүмат кертүне.

2.5. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты ел саен хисап елыннан соң килә торган айның 20 сенә кадәр «Ачык Татарстан» мәгълүмат ресурсына муниципаль берәмлекләр яктылыгында җылылык белән тәэмин итү оешмалары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган инвестиция программалары, аларны финанслауның планлаштырылган һәм факттагы күләмнәре турында мәгълүмат кертүне тәэмин итә.

2.6. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы түбәндәгеләрне тәэмин итә:

а) хисап елыннан соң килә торган айның 20 сенә кадәр Модульгә төбәк һәм муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын, күперләрне һәм башка транспорт һәм инженерлыклык корылмаларын, гомуми файдаланудагы автомобиль юллары челтәре белән ел буе элемтә булмаган авыл торак пунктларына кадәр җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы каты өслекле автомобиль юлларын, федераль әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль

юлларын, күперләрне һәм башка транспорт һәм инженерлыклык корылмаларын төзү, ремонтлау, капиталь ремонтлау, реконструкцияләү чыгымнарына мөнәсәбәтле мәгълүмат кертүне.

Мәгълүмат кертү электрон документлар әйләнеше системасының элемтә каналлары буенча мәгълүматлар формалаштыру яки әлеге Регламентка теркәлгән 4 – 7 нче кушымталар нигезендә Модуль веб-интерфейсының экрандагы формасын тутыру юлы белән тәэмин ителә;

б) муниципаль районнарның, шәһәр округларының һәм җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан кертелгән муниципаль районнарның, шәһәр округларының, җирлекләрнең җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын, күперләрне һәм башка транспорт һәм инженерлыклык корылмаларын ремонтлау, капиталь ремонтлау, реконструкцияләү, төзү чыгымнары турындагы мәгълүматны әлеге Регламентның 2.2 нче пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә Модульгә кертү процессында раслауны.

## 3. Мәгълүматны эшкәртү һәм анализлау тәртибе

3.1. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе түбәндәгеләрне тәэмин итә:

әлеге Регламентның 2.1 – 2.6 нчы пунктлары нигезендә Модульгә мониторингта катнашучылар тарафыннан кертелә торган социаль инфраструктура, тышкы төзекләндерү объектларын, гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, реконструкцияләү, агымдагы һәм капиталь ремонтлау чыгымнары турындагы мәгълүматка регламент ярдәмен;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештерелгән тәртиптә, «Хисаплылыкны үзәкләштереп җыю буенча мәгълүмат-аналитика системасы» мәгълүмат системасыннан файдаланып, дәүләт учреждениеләрен, муниципаль учреждениеләрне агымдагы ремонтлауга факттагы чыгымнар турындагы мәгълүматка регламент ярдәмен;

ел саен, хисап елыннан соң килә торган елның 1 мартына кадәр Татарстан Республикасы буенча тулаем, муниципаль берәмлекләр яктылыгында социаль инфраструктура, тышкы төзекләндерү объектларын, гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм инженерлык коммуникацияләрен төзү, реконструкцияләү, агымдагы һәм капиталь ремонтлау чыгымнары турында аналитик мәгълүмат, узган елга һәм мониторинг еллары буенча динамикада эшчәнлек төрләрен, эшләр төрләрен, финанслау чыганакларын формалаштыруны.

3.2. Әлеге Регламентның 3.1 нче пункты нигезендә әзерләнгән аналитик мәгълүматтан файдаланып формалаштырылган мониторинг нәтиҗәләре ел саен, хисап елыннан соң килә торган айның 30 мартына кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җыелма аналитик мәгълүмат рәвешендә җибәрелә:

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан – төбәк һәм муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын, күперләрне һәм башка транспорт һәм инженерлыклык

корылмаларын, гомуми файдаланудагы автомобиль юллары челтәре белән ел буе элемтә булмаган авыл торак пунктларына кадәр җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы каты өслекле автомобиль юлларын, федераль әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын, күперләрне һәм башка транспорт һәм инженерлыклык корылмаларын төзү, ремонтлау, капиталь ремонтлау, реконструкцияләү чыгымнарына мөнәсәбәтле;

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан – социаль инфраструктура объектларын, җирле әһәмияттәге тышкы төзекләндерү объектларын (юллардан, күперләрдән, юлүткәргечләрдән һәм тоннелльләрдән тыш), инженерлыклык коммуникацияләрен төзү, капиталь ремонтлау, реконструкцияләү, агымдагы ремонт һәм капиталь ремонт чыгымнарына мөнәсәбәтле.

Социаль инфраструктура, тышкы төзекләндерү объектларын, гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм инженерлык коммуникацияләрен төзү, реконструкцияләү, агымдагы һәм капиталь ремонтлау чыгымнары мониторингын гамәлгә ашыру регламентына 1 нче кушымта

Форма

20__ елга
«Татарстан Республикасы Төзелеш комплексы» дәүләт мәгълүмат системасыннан җибәрелә торган социаль өлкә, тышкы төзекләндерү объектларын капиталь ремонтлау, реконструкцияләү, төзү чыгымнары турында мәгълүмат

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Күрсәткечнең мәгънәсе |
|---|---|---|
| 1. | Заказчы исеме | |
| 2. | Заказчының ИНН[1] | |
| 3. | Заказчының КПП[2] | |
| 4. | Муниципаль район исеме | |
| 5. | Юридик зат (эксплуатацияләүче оешма) исеме | |
| 6. | Җирлек исеме | |
| 7. | Юридик затның (эксплуатацияләүче оешма) ИНН | |
| 8. | Юридик затның (эксплуатацияләүче оешма) КПП | |
| 9. | Юридик затның (эксплуатацияләүче оешма) адресы (ФМАС)[3] | |
| 10. | Күчемсез мөлкәт объекты исеме | |
| 11. | Күчемсез мөлкәт объектының кадастр саны | |
| 12. | Күчемсез мөлкәт объектын тәнгәлләштерү коды | |
| 13. | Күчемсез мөлкәт объектының (бина, корылма) адресы (ФМАС) | |
| 14. | Эшчәнлек төре | |
| 15. | Эш төре [4] | |
| 16. | Гомуми мәйдан, эш күләме | |
| 17. | Ягып җылытыла торган мәйдан | |
| 18. | Мәйданны, эш күләмен үлчәү берәмлеге | |
| 19. | Куәт | |

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Күрсәткечнең мәгънәсе |
|---|---|---|
| 20. | Куәтне үлчәү бермәлеге | |
| 21. | Эшне башкару өчен нигез (финанслар белән эш итү документлары) | |
| 22. | Төзелеш планлаштырылган вакытлар, ел | |
| 22.1. | төзелеш башлану | |
| 22.2. | төзелеш тәмамлану | |
| 23. | Төзелешнең факттагы вакытлары, ел | |
| 23.1. | төзелеш башлану | |
| 23.2. | төзелеш тәмамлану | |
| 24. | Капитал салулар, тулаем объект буенча план, сум, шул исәптән: | |
| 24.1. | җәлеп ителгән акча | |
| 24.2. | фелераль бюджет | |
| 24.3. | Татарстан Республикасы бюджеты | |
| 24.4. | җирле бюджет | |
| 25. | Капитал салулар, билгеләнгән чор ахырындагы елга план, сум, шул исәптән: | |
| 25.1. | җәлеп ителгән акча | |
| 25.2. | фелераль бюджет | |
| 25.3. | Татарстан Республикасы бюджеты | |
| 25.4. | җирле бюджет | |
| 26. | Капитал салулар, факт, сум | |
| 27. | Капитал салулар, түләү буенча факт, сум | |
| 28. | Тәмамланмаган булу сәбәбе | |
| 29. | Чор башы | |
| 30. | Чор ахыры | |
| 31. | Бушату көне, вакыты | |

[1]ИНН – салым түләүченең шәхси тәңгәлләштерү саны;
[2]КПП – исәпкә кую сәбәбе коды;
[3]ФМАС – федераль мәгълүмат адреслы системасы;
[4]Төзелеш, реконструкция, капиталь ремонт

Социаль инфраструктура, тышкы төзекләндерү объектларын, гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм инженерлык коммуникацияләрен төзү, реконструкцияләү, агымдагы һәм капиталь ремонтлау чыгымнары мониторингын гамәлгә ашыру регламентына 2 нче кушымта

Форма

20___ елга
Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, муниципаль районнарның, шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан башкарыла торган социаль өлкә объектларын капиталь ремонтлау, реконструкцияләү, төзү чыгымнары турында мәгълүмат

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Күрсәткечнең мәгънәсе |
|---|---|---|
| 1. | Заказчы исеме | |
| 2. | Заказчының ИНН[1] | |
| 3. | Заказчының КПП[2] | |
| 4. | Муниципаль район исеме | |
| 5. | Юридик зат (эксплуатацияләүче оешма) исеме | |
| 6. | Салым түләүченең – юридик затның (эксплуатацияләүче оешма) шәхси тәңгәлләштерү саны | |
| 7. | Юридик затны (эксплуатацияләүче оешма) исәпкә кую сәбәбе коды | |
| 8. | Юридик зат (эксплуатацияләүче оешма) адресы (ФМАС)[2] | |
| 9. | Оешма – филиал (аерылып чыккан структур бүлекчә) исеме | |
| 10. | Оешма – филиал (аерылып чыккан структур бүлекчә) адресы (ФМАС) | |
| 11. | Күчемсез мөлкәт объекты исеме | |
| 12. | Күчемсез мөлкәт объектының кадастр саны | |
| 13. | Күчемсез мөлкәт объекты (бина, корылма) адресы (ФМАС) | |
| 14. | Эшчәнлек төре | |
| 15. | Эш төре[4] | |
| 16. | Гомуми мәйдан | |
| 17. | Ягып җылытыла торган мәйдан | |

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Күрсәткечнең мәгънәсе |
|---|---|---|
| 18. | Мәйданны үлчәү берәмлеге | |
| 19. | Куәт | |
| 20. | Куәтне үлчәү берәмлеге | |
| 21. | Эшне башкару өчен нигез (финанслар белән эш итү документлары) | |
| 22. | Төзелеш планлаштырылган вакытлар, ел | |
| 22.1. | төзелеш башлану | |
| 22.2. | төзелеш тәмамлану | |
| 23. | Төзелешнең факттагы вакытлары, ел | |
| 23.1. | төзелеш башлану | |
| 23.2. | төзелеш тәмамлану | |
| 24. | Капитал салулар, тулаем объект буенча план, сум, шул исәптән: | |
| 24.1. | җәлеп ителгән акча | |
| 24.2. | фелераль бюджет | |
| 24.3. | Татарстан Республикасы бюджеты | |
| 24.4. | җирле бюджет | |
| 25. | Капитал салулар, хисап елы планы, сум, шул исәптән: | |
| 25.1. | җәлеп ителгән акча | |
| 25.2. | фелераль бюджет | |
| 25.3. | Татарстан Республикасы бюджеты | |
| 25.4. | җирле бюджет | |
| 26. | Капитал салулар, факт, сум | |
| 27. | Капитал салулар, түләү буенча факт, сум | |
| 28. | Тәмамланмаган булу сәбәбе | |
| 29. | Хисап чоры, мәгълүматлар формалаштыру елы | |

[1]ИНН – салым түләүченең шәхси тәңгәлләштерү саны;

[2]КПП – исәпкә кую сәбәбе коды;

[3]ФМАС – федераль мәгълүмат адреслы системасы;

[4]Төзелеш, реконструкция, капиталь ремонт

Социаль инфраструктура, тышкы төзекләндерү объектларын, гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм инженерлык коммуникацияләрен төзү, реконструкцияләү, агымдагы һәм капиталь ремонтлау чыгымнары мониторингын гамәлгә ашыру регламентына 3 нче кушымта

Форма

20___елга муниципаль районнарның, шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан башкарылган җирле әһәмияттәге тышкы төзекләндерү объектларын (җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларыннан, күперләрдән, юлүткәргечләрдән һәм тоннельләрдән тыш) төзү, реконструкцияләү, ремонтлау, капиталь ремонтлау чыгымнары турында мәгълүмат

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Күрсәткечнең мәгънәсе |
|---|---|---|
| 1. | Заказчы исеме | |
| 2. | Заказчының ИНН[1] | |
| 3. | Заказчының КПП[2] | |
| 4. | Муниципаль район, шәһәр округы исеме | |
| 5. | Җирлек исеме | |
| 6. | Тышкы төзекләндерү объекты төре[3] | |
| 7. | Эшне үлчәү берәмлеге[4] | |
| 8. | Эш күләме | |
| 9. | Эш төре[5] | |
| 10. | Эшне башкару өчен нигез (финанслар белән эш итү документларны) | |
| 11. | Эшләрне башкару планлаштырылган вакытлар, ел | |
| 11.1. | башлану | |
| 11.2. | тәмамлану | |
| 12. | Эшне башкаруның факттагы вакытлары, ел | |
| 12.1. | башлану | |
| 12.2. | тәмамлану | |
| 13. | Капитал салулар, тулаем объект төре буенча план, сум, шул исәптән: | |
| 13.1. | җәлеп ителгән акча | |
| 13.2. | фелераль бюджет | |

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Күрсәткечнең мәгънәсе |
|---|---|---|
| 13.3. | Татарстан Республикасы бюджеты | |
| 13.4. | жирле бюджет | |
| 14. | Капитал салулар, хисап елы планы, сум, шул исәптән: | |
| 14.1. | җәлеп ителгән акча | |
| 14.2. | фелераль бюджет | |
| 14.3. | Татарстан Республикасы бюджеты | |
| 14.4. | жирле бюджет | |
| 15. | Капитал салулар, факт, сум | |
| 16. | Капитал салулар, түләү буенча факт, сум | |
| 17. | Тәмамланмаган булу сәбәбе | |
| 18. | Хисап чоры, мәгълүматлар формалаштыру елы | |

[1]ИНН – салым түләүченең шәхси тәңгәлләштерү саны;
[2]КПП – исәпкә кую сәбәбе коды;
[3] Парклар, скверлар;
юл читендәге һәм яр буйларындагы яшел массивлар;
урамнарны яктырту (яктырткычлар);
су саклау зоналары;
ясалма утыртмалар белән ныгытылган ярлар һәм дамбалар;
ясалма утыртмаларсыз ныгытылган ярлар һәм дамбалар;
плотиналар;
урамнарны, юлларны һәм яр буйларын яктырту челтәрләре;
зиратлар, терлек каберлекләре (биотермик чокырлар);
башка корылмалар (пляжлар, фонтаннар, һәйкәлләр һ.б.);
[4]Кв.метр, гектар, километр, метрлар озынлыкта, данә;
[5]Төзелеш, реконструкция, ремонт, капиталь ремонт

Социаль инфраструктура, тышкы төзекләндерү объектларын, гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм инженерлык коммуникацияләрен төзү, реконструкцияләү, агымдагы һәм капиталь ремонтлау чыгымнары мониторингын гамәлгә ашыру регламентына 4 нче кушымта

Форма

20___елның 1 гыйнвары хәленә карата
гомуми файдаланудагы автомобиль юллары реестры

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Күрсәткечнең мәгънәсе |
|---|---|---|
| 1. | Муниципаль район, шәһәр округы исеме | |
| 2. | Җирлек исеме | |
| 3. | Әһәмиятенә бәйле рәвештә юлның классификациясе | |
| 4. | Юлның тәңгәлләштерелгән саны | |
| 5. | Юлның исеме | |
| 6. | Категориясе | |
| 7. | Юлның гомуми озынлыгы (куәте), километр | |
| 8. | Юлның гомуми мәйданы (куәте), кв.метр | |
| 9. | Участок [1] | |
| 9.1. | участок башы, километр | |
| 9.2. | участок ахыры, километр | |
| 9.3. | участок өслегенең төре | |
| 9.4. | участокның мәйданы, мең кв.метр | |
| [1] Юлның барлык участоклары китерелә | | |

Социаль инфраструктура, тышкы төзекләндерү объектларын, гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм инженерлык коммуникацияләрен төзү, реконструкцияләү, агымдагы һәм капиталь ремонтлау чыгымнары мониторингын гамәлгә ашыру регламентына 5 нче кушымта

Форма

20___елның 1 гыйнвары хәленә карата күперләр һәм башка транспорт һәм инженерлык корылмалары реестры

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Күрсәткечнең мәгънәсе |
|---|---|---|
| 1. | Муниципаль район, шәһәр округы исеме | |
| 2. | Җирлек исеме | |
| 3. | Әһәмиятенә бәйле рәвештә юлның классификациясе | |
| 4. | Юлның тәңгәлләштерелгән саны | |
| 5. | Юлның исеме | |
| 6. | Юлдагы объектның тәңгәлләштерелгән саны | |
| 7. | Юлдагы объектның исеме | |
| 8. | Объектның төре | |
| 9. | Объектның тасвирламасы | |
| 10. | Объектның тасвирламасын үлчәү берәмлеге | |
| 11. | Төзелеш датасы, ел | |
| 12. | Соңгы реконструкция датасы, ел | |
| 13. | Соңгы капиталь ремонт датасы, ел | |
| 14. | Соңгы ремонт датасы, ел | |

Социаль инфраструктура, тышкы төзекләндерү объектларын, гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм инженерлык коммуникацияләрен төзү, реконструкцияләү, агымдагы һәм капиталь ремонтлау чыгымнары мониторингын гамәлгә ашыру регламентына 6 нчы кушымта

Форма

20__елга гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, реконструкцияләү, ремонтлау, капиталь ремонтлау чыгымнары турында мәгълүмат

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Күрсәткечнең мәгънәсе |
|---|---|---|
| 1. | Муниципаль район, шәһәр округы исеме | |
| 2. | Җирлек исеме | |
| 3. | Әһәмиятенә бәйле рәвештә юлның классификациясе[1] | |
| 4. | Юлның тәңгәлләштерелгән саны | |
| 5. | Юлның исеме | |
| 6. | Категориясе | |
| 7. | Юл участогы, башы, километр | |
| 8. | Юл участогы, ахыры, километр | |
| 9. | Эш төре[2] | |
| 10. | Участок өслегенең төре | |
| 11. | Участокның мәйданы, мең кв.метр | |
| 12. | Подрядчы оешма | |
| 13. | Эшне башкару өчен нигез (финанслар белән эш итү документларны) | |
| 14. | Эшне башкару планлаштырылган вакытлар, ел | |
| 14.1. | башлану | |
| 14.2. | тәмамлану | |
| 15. | Эшне башкаруның факттагы вакытлары, ел | |
| 15.1. | башлану | |
| 15.2. | тәмамлану | |
| 16. | Капитал салулар, тулаем юл буенча план, сум, шул исәптән: | |
| 16.1. | җәлеп ителгән акча | |
| 16.2. | фелераль бюджет | |

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Күрсәткечнең мәгънәсе |
|---|---|---|
| 16.3. | Татарстан Республикасы бюджеты | |
| 16.4. | жирле бюджет | |
| 16.5. | муниципаль юл фонды | |
| 17. | Капитал салулар, хисап елы планы, сум, шул исәптән: | |
| 17.1. | җәлеп ителгән акча | |
| 17.2. | фелераль бюджет | |
| 17.3. | Татарстан Республикасы бюджеты | |
| 17.4. | жирле бюджет | |
| 18. | Капитал салулар, факт, сум | |
| 19. | Капитал салулар, түләү буенча факт, сум | |
| 20. | Тәмамланмаган булу сәбәбе | |
| 21. | Хисап чоры, мәгълуматлар формалаштыру елы | |

[1] Федераль әһәмияттәге автомобиль юллары, төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары, муниципаль районның, шәһәр округының, җирлекнең җирле әһәмияттәге автомобиль юллары;
[2] Төзелеш, реконструкция, ремонт, капиталь ремонт

Социаль инфраструктура, тышкы төзекләндерү объектларын, гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм инженерлык коммуникацияләрен төзү, реконструкцияләү, агымдагы һәм капиталь ремонтлау чыгымнары мониторингын гамәлгә ашыру регламентына 7 нче кушымта

Форма

20___елга күперләрне һәм башка транспорт һәм инженерлык корылмаларын төзү, реконструкцияләү, ремонтлау, капиталь ремонтлау чыгымнары турында мәгълүмат

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Күрсәткечнең мәгънәсе |
|---|---|---|
| 1. | Муниципаль район, шәһәр округы исеме | |
| 2. | Җирлек исеме | |
| 3. | Әһәмиятенә бәйле рәвештә юлның классификациясе | |
| 4. | Юлның тәңгәлләштерелгән саны | |
| 5. | Юлның исеме | |
| 6. | Юлдагы объектның тәңгәлләштерелгән саны | |
| 7. | Юлдагы объектның исеме | |
| 8. | Юлдагы объектның төре | |
| 9. | Юлдагы объектның тасвирламасы | |
| 10. | Юлдагы объектның тасвирламасын үлчәү берәмлеге | |
| 11. | Эш күләме | |
| 12. | Эш күләмен үлчәү берәмлеге | |
| 13. | Эш төре | |
| 14. | Эшне башкару өчен нигез (финанслар белән эш итү документлары) | |
| 15. | Эшне башкару планлаштырылган вакытлар, ел | |
| 15.1. | башлану | |
| 15.2. | тәмамлану | |
| 16. | Эшне башкаруның факттагы вакытлары, ел | |
| 16.1. | башлану | |
| 16.2. | тәмамлану | |
| 17. | Капитал салулар, тулаем объект буенча план, сум, шул исәптән: | |
| 17.1. | җәлеп ителгән акча | |

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Күрсәткечнең мәгънәсе |
|---|---|---|
| 17.2. | фелераль бюджет | |
| 17.3. | Татарстан Республикасы бюджеты | |
| 17.4. | җирле бюджет | |
| 17.5. | муниципаль юл фонды | |
| 18. | Капитал салулар, хисап елы планы, сум, шул исәптән: | |
| 18.1. | җәлеп ителгән акча | |
| 18.2. | фелераль бюджет | |
| 18.3. | Татарстан Республикасы бюджеты | |
| 18.4. | җирле бюджет | |
| 19. | Капитал салулар, факт, сум | |
| 20. | Капитал салулар, түләү буенча факт, сум | |
| 21. | Тәмамланмаган булу сәбәбе | |
| 22. | Хисап чоры, мәгълүматлар формалаштыру елы | |